| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Брюшлинского сельского<br>поселения Менделеевского<br>муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге Советы |

---

| | |
|---|---|
| Р Е Ш Е Н И Е<br>2020 елның 27 ноябреннән | К А Р А Р<br>№13 |

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмнәрен, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августыннан 658 нче номерлы «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 18 маендагы 90 нчы номерлы карары белән расланган Муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 18 маендагы 90 нчы номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә, 2020 елның 1 октябреннән арттырырга.
3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәплә өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.
4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының

рәсми сайтында www.mendelevsk.tatarstan.ru «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Бөрешле авыл җирлеге
Советы Рәисе Л.А. Смирнова